ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 апрель, 2016 ел № 7/16

Территориаль иҗтимагый үзидарәләр чикләрен билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 4, 28 маддәләре, Шәһәр Советының 2014 елның 17 апрелендәге 30/18 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәләр чикләрен билгеләргә:

1) Яр Чаллы шәһәренең Үзәк районы территориясендә 1 кушымтага нигезләнеп;

2) Яр Чаллы шәһәренең Комсомол районы территориясендә 2 кушымтага нигезләнеп.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
7/16 нчы Карарына
1 нче кушымта
7 апрель, 2016 ел

Яр Чаллы шәһәренең Үзәк районы территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр чикләре:

1. «12 комплекс» ТИҮ:

– 12 торак комплексы чикләрендәге Рәис Беляев проспектының Раскольников урамы белән кисешү почмагыннан, Раскольников урамы буйлап Хәсән Туфан проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Хәсән Туфан проспекты буйлап Чулман проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Чулман проспекты буйлап Рәис Беляев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Рәис Беляев проспекты буйлап Раскольников урамы белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.




2. «41 комплекс» ТИҮ:

– 41 торак комплексы чикләрендәге Халыклар Дуслыгы проспектының Шамил Усманов урамы белән кисешү почмагыннан, Шамил Усманов урамы буйлап Рәис Беляев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Рәис Беляев проспекты буйлап Сөембикә проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Сөембикә проспекты буйлап Халыклар Дуслыгы проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Халыклар Дуслыгы проспекты буйлап Шамил Усманов урамы белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.




3. «59 комплекс» ТИҮ:

59 торак комплексы чикләрендәге Академик Королев урамының Мәскәү проспекты белән кисешү почмагыннан, Мәскәү проспекты буйлап Кол Гали бульвары белән кисешкәнгә кадәр, Кол Гали бульвары буйлап Әхмәтшин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Әхмәтшин урамы буйлап Академик Королев урамы белән кисешкәнгә кадәр, Академик Королев урамы буйлап Мәскәү проспекты белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.




4. «35 комплекс» ТИҮ:

– 35 торак комплексы чикләрендәге Марат Йосыпов урамының «Прибрежный» торак районы, «Берег» микрорайоны, «Чаллы ЯР» поселогы чиге белән кисешү почмагыннан, «Прибрежный» торак районы, «Берег» микрорайоны, «Чаллы ЯР» поселогы чиге буйлап Халыклар Дуслыгы проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Халыклар Дуслыгы проспекты буйлап Раскольников урамы белән кисешкәнгә кадәр, Раскольников урамы буйлап Марат Йосыпов урамы белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.




5. «4, 5 комплекслар» ТИҮ:

– 4 һәм 5 торак комплекслар чикләрендәге Рәис Беляев проспектының Тынычлык проспекты белән кисешү почмагыннан, Тынычлык проспекты буйлап Ершов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Ершов урамы буйлап Төзүчеләр бульвары белән кисешкәнгә кадәр, Төзүчеләр бульвары буйлап Хәсән Туфан проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Хәсән Туфан проспекты буйлап Мәскәү проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Мәскәү проспекты буйлап Рәис Беляев проспекты белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.



**6. «1, 3 комплекслар» ТИҮ:**

– 1 һәм 2 комплекслар чикләрендәге Хәсән Туфан проспектының Тынычлык проспекты белән кисешү почмагыннан, Тынычлык проспекты буйлап Вахитов ис. проспект белән кисешкәнгә кадәр, Вахитов ис. проспект буйлап Мәскәү проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Мәскәү проспекты буйлап Академик Рубаненко урамы белән кисешкәәгә кадәр, Академик Рубаненко урамы буйлап Энтузиастлар бульвары белән кисешкәнгә кадәр, Энтузиастлар бульвары буйлап Хәсән Туфан проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Хәсән Туфан проспекты буйлап Тынычлык проспекты белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.



Шәһәр Советының
7/16 нчы Карарына
2 нче кушымта
7 апрель, 2016 ел

Яр Чаллы шәһәренең Комсомол районы территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр чикләре:


1. «Старые Челны» ТИҮ:

– Е.Н. Батенчук ис. урамның Полевая урамы белән кисешү почмагынна, Полевая урамы буйлап Причальная урамы белән кисешкәнгә кадәр, Причальная урамы буйлап Комсомол Яр буе белән кисешкәнгә кадәр, Комсомол Яр буе буйлап Үзәк урам белән кисешкәнгә кадәр, Үзәк урам буйлап Гагарин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Гагарин урамы буйлап Салих Сәйдәшев ис. бульвар белән кисешкәнгә кадәр, Салих Сәйдәшев ис. бульвар буйлап Пугачев урамы белән кисешкәнгә кадәр, Пугачев урамы буйлап Е.Н. Батенчук ис. урам белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.




2. «Новый» ТИҮ:

– 17 А-III микрорайоны чикләрендәге торак йортлар, Татарстанга 40 ел урамының Профсоюзная урамы белән кисешү почмагыннан, Профсоюзная урамы буйлап Яр Чаллы проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Яр Чаллы проспекты буйлап Сарман тракты белән кисешкәнгә кадәр, Сарман тракты буйлап Татарстанга 40 ел урамы белән кисешкәнгә кадәр торак йортларны кертеп.




3. «Кызыл Чаллы» ТИҮ:

– Жданов урамының Лиза Чайкина урамы белән кисешү почмагыннан, Лиза Чайкина урамы буйлап Мәләкәс елгасы яр буе зонасы буенча Яр Чаллы проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Яр Чаллы проспекты буйлап Профсоюзная урамы белән кисешкәнгә кадәр, Профсоюзная урамы буйлап Жданов урамы белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.



4. «Орловка» ТИҮ:

– Яр Чаллы проспектының Мироновка урамы белән кисешү почмагыннан, Мироновка урамы буйлап Сергей Титов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Сергей Титов урамы буйлап Яр Чаллы проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Яр Чаллы проспекты буйлап Орловская урамы белән кисешкәнгә кадәр, Орловская урамы буйлап Нәриманов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Нәриманов урамы буйлап Мәскәү проспекты белән кисешкәнгән кадәр, Мәскәү проспекты буйлап Иван Утробин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Иван Утробин урамы буйлап Академик Королев урамы белән кисешкәнгә кадәр, Академик Королев урамы буйлап Орловская урамы белән кисешкәнгә кадәр, Советская урамы буенча, Советскаяя урамы буйлап Набережная урамы белән кисешкәнгә кадәр, Набережная урамы буйлап Челнинка елгасының яр буе линиясе буенча Яр Чаллы проспекты белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.



5. «Замелекесье-шәхси сектор»:

– Казан проспектының Мәләкәс урамы белән кисешү почмагыннан, Мәләкәс урамы буйлап Аэродромная урамы белән кисешкәнгә кадәр, Аэродромная урамы буйлап В.Гостев урамы белән кисешкәнгә кадәр, В.Гостев урамы буйлап Жданов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Жданов урамы буйлап Н.Якупов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Н.Якупов урамы буйлап В. Гостев урамы белән кисешкәнгә кадәр, В. Гостев урамы буйлап В. Фоменко проспекты белән кисешкәнгә кадәр, В.Фоменко проспекты буйлап Мәләкәс урамы белән кисешкәнгә кадәр, Мәләкәс урамы буйлап Дмитрий Прохоренко урамы белән кисешкәнгә кадәр, Дмитрий Прохоренко урамы буйлап Казан проспекты белән кисешкәнгә кадәр торак йортлар.

